| Республика Татарстан<br>Лешев-Тамакское сельское поселение Сармановского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Ләшәү Тамак<br>авыл җирлеге |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2022елның 14 июле** **№ 11**

**“Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Ләшәү Тамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында”Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2020 елның 20 май 6 нчы санлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2022 елның 16 апрель 102-ФЗ санлы Федераль законының 1нче пунктына нигезләнеп, Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. “Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау турында” Ләшәү Тамак авыл җирлеге Советының 2020 елның 20 май 6 нчы санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 5нче маддәнең 6нчы бүлегендәге 14нче пунктка түбәндәге эчтәлектәге “г” пунктчасын өстәргә:

“г) Федераль казначылык органында, Татарстан Республикасының финанс органында, муниципаль берәмлекнең финанс органында, Россия Федерациясенең дәүләт бюджеттан тыш фонды белән идарә итү органында (Россия Федерациясенең Үзәк банкы учреждениесендә яки кредит оешмасында) счеты ачылмаган бурычлы булган казна учреждениесеннән акча, шул исәптән суд чыгымнарын, түләтү турында;”;

2) 15нче маддәнең 2нче пунктындагы 4нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Советы рәисе И.З.Хабибуллин